Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ №5

2019 ел 19 июнь

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ, 1996 елның 12 январендәге «Җирләү һәм җирләү эше турында» №8-ФЗ федераль законнар нигезендә, 2007 елның 18 маендагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» №196 карары нигезендә, Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасың Әлмәт шәһәрендәге идарәсе белән (районара) килешеп

Рус Акташы авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2019 елның 1 июленнән 5 946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә.
2. Әлмәтмуниципаль районы Рус Акташы авылҗирлеге Уставына үзгәрешләр нетеркәгәннәнсоң Рус Акташы, авылы Тозүчелер урамы 14 йорт, Акташ станциясе - контора бинасы, территория ләрендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка хәбәритәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты “Интернет” челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2019 елның 1 июленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Рус Акташы авылы
башкарма комитеты җитәкчесе С.А. Белоногов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авылы башкарма
комитетының 2019 елның
19 июнендәге №5
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 84,25 |
| 2 | Гробны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне тапшыру | 3 414,27 |
| 3 | Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен ) зиратка алып бару | 530,44 |
| 4 | Кабер (казу һәм күмү) | 1 917,51 |
| | Барлыгы | 5 946,47 |

Рус Акташы авылы
башкарма комитеты җитәкчесе С.А. Белоногов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авылы башкарма
комитетының 2019 елның
19 июнендәге №5
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 84,25 |
| 2 | Мәетне кәфенгә төрү | 2 001,70 |
| 3 | Гробны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне тапшыру | 1 412,58 |
| 4 | Мәрхүмнең гәүдәсен ( мәетен ) зиратка алып бару | 530,44 |
| 5 | Кабер (казу һәм күмү) | 1 917,50 |
| | Барлыгы | 5 946,47 |

Рус Акташы авылы
башкарма комитеты җитәкчесе С.А. Белоногов